БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 гыйнвар 2022 ел № 101

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Даими нигездә дәүләт серенә рөхсәте булган гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номрлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (2020 елның 21 маендагы редакциядә), «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы карары, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 9 нчы кушымтасындагы 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәрне элек билгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан югарырак муниципаль хезмәт вазыйфасы төркеменә билгеләгән очракта, үзе билгән вазыйфа төркеме өчен беренче классслы чин бирүгә кадәр

классլы чин өчен оклад күләмен исәпләү 3 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

Муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнәк муниципаль хезмәт вазыйфасы төркеменә билгеләгән һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класс чины бирелгән очракта, классլы чин өчен оклад күләмен исәпләү 7 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.»;

1.2. Карарның 10 нчы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләү күләме һәм аны түләү тәртибе**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләү яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хокукый акты белән билгеләнә һәм хезмәт хакының 1 процентыннан артмаган күләмдә түләнә, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, муниципаль хезмәткәр элек үзе биләгән вазыйфадагы хезмәт хакына караганда азрак хезмәт хакы булган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очрактан тыш, ул вакытта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата керемен элек биләгән вазыйфасы буенча акчалата керем күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.»;

2. Әлеге карарның 1.1 пунктында кертелгән үзгәрешләр 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Р.М. Ильясовка 2022 елның 1 мартына кадәр гамәлдәге федераль законнар нигезендә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык өстәмә (вазыйфаи окладтан процентларда) күләмен билгеләү тәртибен өйрәнергә һәм тәкъдимнәр кертергә.

4. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин